ҖОМГА
9 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 32 (5832)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ТАТАРСТАННЫҢ XX ЕЛЛЫГЫН ЯҢА УҢЫШЛАР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК

Шушы елның 25 нче июнендә Татарстан АССР ның төзелүенә егерме ел тула. Республикабызның хезмәт ияләре бу тарихи көнне яңа уңышлар белән каршылау өчен большевистик көрәш җәелдерәләр. Завод, фабрикаларда, колхоз һәм совхозларда, дәүләт учреждениеләрендә социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте көннән-көн киң колач ала бара.

Кешелекнең бөек даһилары Ленин һәм Сталин тарафыннан төзелгән Татарстан республикасы бу егерме ел эчендә гаят зур тарихи юл үтте. Бөек Октябрь Революциясенә кадәр царизмның ярым колониясе булып яшәгән, ачлыкка, хәерчелеккә дучар ителгән Казан губернасы—хәзерге Татарстан Совет власте елларында танымаслык булып үзгәрде.

Егерме ел вакыт тарих өчен иң кыска һәм иң кечкенә чор булып санала. Ә, совет кешеләре—һәр төрле эксплоатациядән һәм капиталистик коллыктан мәңгегә азат ителгән социализм иле кешеләре кыска гына вакыт эчендә нинди зур эшләр башкаралар. Моны без бөек илебезнең аерылмас өлеше булган Татарстан мисалендә бик ачык күрәбез. Татарстан республикасы үзе яшәвенең егерме елы эчендә индустриаль - аграр республика булып әверелде. Сталинчыл бишьеллыклар аның йөзен танымаслык итеп үзгәрттеләр. Элекке вакытта яшәп килгән ярым кустарь типындагы вак предприятиеләр урнына, техниканың соңгы яңалыкларын үз эченә алган зур гигантлар үсеп чыкты, авыл хуҗалыгы социалистик нигездә яңа баштан корылды. Республикабызның хезмәт ияләре культуралы, таза тормышка ия булдылар. Татарстан картасы күп санлы яңа предприятиеләр белән, колхозлар, совхозлар, машина-трактор станцияләре белән, мәктәпләр, клублар, уку өйләре, китепханәләр, больницалар, балалар бакчалары, ясләләр һәм башка шундый культура учреждениеләре белән бизәлде. Боларның барсын да республикабызның хезмәт ияләре үз күзләре белән күреп беләләр һәм аңа карап чын күңелләреннән шатланалар.

Бу тарихи уңышларны яулап алу җиңел булмады. Царизм вакытында йөз еллар буенча изелеп килгән һәм үзенең техникасы агач сукадан гыйбарәт булган өлкәне кыска гына вакыт эчендә алдынгы, индустриаль республика итү өчен зур көч, энергия куярга туры килде. Бу бәхетле, таза тормышны, культуралы, шат тормышны безгә данлыклы коммунистлар партиясе, республикабызны оештыруның инициаторлары булган даһи Ленин һәм Сталин тәэмин иттеләр, бу уңышлар бөек рус халкының зур ярдәме һәм турыдан-туры булышлыгы белән яулап алындылар.

Данлыклы егерме ел эчендә республикабыз ирешкән бу гүзәл уңышлар өчен без, иң беренче чиратта, Ленин—Сталин партиясенә, бөек рус халкына бурычлыбыз. Менә шуңа күрә дә республикабызның хезмәт ияләре большевиклар партиясе тирәсенә, аның Үзәк Комитеты тирәсенә моңар кадәр булганга караганда да ныграк тупланганнар һәм бөек Ватан өчен үзләренең каннарын гына түгел, бәлки кирәк булса, тормышларын да бирергә хәзер торалар.

Әйе, Ватаныбызның башка өлкәләрендәге, крайларындагы һәм республикаларындагы кебек үк, Татарстан республикасының да уңышлары гаят дәрәҗәдә зурлар һәм күренеклеләр. Бу казанышлар белән Татарстан хезмәт ияләре бик урынлы рәвештә горурланалар. Ләкин безнең партиябез ирешелгән уңышлар белән тынычланып калмый. Аның программ бурычы туктаусыз алга бару һәм коммунизмның тәмам җиңүенә ирешү. Бу исә, бездән тагын да җиддиерәк һәм киеренкерәк эш таләп итә, бүген кичәгедән, ә иртәгә бүгенгедән яхшырак эшләүне, тагын да тырышыбрак һәм үз-үзеңне аямыйча эшләүне таләп итә. Димәк, уңышлар белән масаймаска, алда торган бурычларны үтәү көрәшенә барлык эшчеләрне, колхозчыларны, интеллигенцияне тупларга кирәк.

1940 нчы ел киң массаның яңа хәрәкәте белән башланып китте. Илебезнең эшчеләр сыйнфы, колхозчы крестьяннәре Сталинчыл өченче бишьеллык планның өченче елында тагын да зуррак уңышларга ирешү өчен сугышчан көрәш башладылар. Шәһәрдә һәм авылда социалистик ярыш байрагы тагын да югарырак күтәрелде. Татарстанда бу ярыш республиканың XX еллыгын яңа җиңүләр белән каршылау лозунгысы астында бара. Социалистик промышленностьта хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең бишьеллык планын дүрт елда үтәү өчен! Авыл хуҗалыгында һәр елны 8 миллиард пот иген уңышы алуга ирешү өчен! Капитализмның мирасы булган укый-яза белмәүчелекне тәмам бетерү өчен! Формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураның тагын да чәчәк атуы өчен! Татарстанның XX еллыгы уңае белән башланган социалистик ярыш байрагына әнә шул лозунглар язылган. Массаның үзе тарафыннан күтәрелгән бу бурычларны уңышлы үтәү өчен көрәш һәм бу көрәшкә барлык хезмәт ияләрен туплау—партия, профсоюз һәм комсомол оешмаларының сугышчан бурычлары булып тора.

Республикабызның барлык оешмалары, бөтен җәмагатчелек Татарстанның XX еллыгына хәзерлек эшенә актив рәвештә катнашырга, промышленность предприятиеләрендә, авыл хуҗалыгында киң җәелеп бара торган социалистик ярышка оператив җитәкчелек итәргә тиешләр.

Республикабыз үткән тарихи юл белән хезмәт ияләрен ныклап таныштырырга, партия-политик эшне һәм масса-аңлату эшләрен данлыклы юбилейгә хәзерлек эшләре белән бергә бәйләп алып барырга кирәк. Татарстанның мех промышленносте эшчеләре мөраҗәгатен һәм авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика киңәшмәсе мөраҗәгатен барлык урыннарда ныклап өйрәнергә, анда билгеләнгән чараларны практик тормышка ашыру өчен җидди көрәш җәелдерергә кирәк. Партия, профсоюз, комсомол оешмаларының төп бурычлары әнә шулардан—орденлы республиканың данлыклы юбилеен яңа уңышлар белән каршылау өчен көрәшүдән гыйбарәт.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
УКАЗЫ
Кызыл Байраклы Балтык флотының „Щ—311“ су асты көймәсен „Кызыл байрак“ ордены белән бүләкләү турында

Командованиенең сугыш заданиеләрен үтәгән вакытта личный состав тарафыннан күрсәтелгән батырлык һәм кыюлык өчен Кызыл Байраклы Балтык флотының „Щ—311“ су асты көймәсен „Кызыл Байрак“ ордены белән **бүләкләргә.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 февраль, 1940 ел.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

7 нче февральдә фронтта артык бер нәрсә дә булмады. Безнең авиация күзәтү очышлары һәм хәрби очышлар үткәрде.

1939 нчы елның 4 нче ноябрендә СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. И. Калинин Советлар Союзы Геройларына „Алтын Йолдыз“ медальләре тапшырды. РӘСЕМДӘ: Советлар Союзы Герое майор Г. П. Кравченко беренче һәм икенче „Алтын Йолдыз“ медальләрен алганнан соң. С. Лоскутов фотосы (ТАСС фото-клишесе).

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
УКАЗЫ
Капитан—лейтенант Ф. Г. Вершинингa Советлар Союзы Герое исме бирү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Ленин** ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале белән берлектә капитан—лейтенант Федор Григорьевич Вершининга Советлар Союзы Герое исме бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 февраль, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
УКАЗЫ
Капитан—лейтенант А. В. Трипольскийга Советлар Союзы Герое исме бирү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Ленин** ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале белән берлектә капитан—лейтенант Александр Владимирович **Трипольскийга Советлар Союзы Герое** исме бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 февраль, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
УКАЗЫ
Кече командир А. И. Белогуровка, лейтенант Г. С. Пинчукка һәм өлкән лейтенант В. М. Харламовка Советлар Союзы Герое исме бирү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Ленин** ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале белән берлектә **Советлар Союзы Герое** исме бирергә:

1. Кече командир Александр Иванович **Белогуровка.**
2. Лейтенант Григорий Сергеевич **Пинчукка.**
3. Өлкән лейтенант Василий Максимович **Харламовка.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 февраль, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
УКАЗЫ
Өлкән лейтенант И. Д. Борисовка, капитан А. И. КРОХАЛЕВКА һәм капитан В. И. РАКОВКА Советлар Союзы Герое исме бирү турында

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткән өчен **Ленин** ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале белән берлектә **Советлар Союзы Герое** исме бирергә:

1. Өлкән лейтенант Иван Дмитриевич **Борисовка.**
2. Капитан Анатолий Ильич **Крохалевка.**
3. Капитан Василий Иванович **Раковка.**

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 февраль, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
УКАЗЫ
Кызыл Байраклы Балтык флотының „С—1“ су асты көймәсен „Кызыл байрак“ ордены белән бүләкләү турында

Командованиенең сугыш заданиеләрен үтәгән вакытта личный состав тарафыннан күрсәтелгән батырлык һәм кыюлык өчен Кызыл байраклы Балтык флотының „С—1“ су асты көймәсен „Кызыл байрак“ ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
7 февраль, 1940 ел.

Чит илләрдә

ПАРИЖДА СОВЕТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНӘ ПОЛИЦИЯ ҺӨҖҮМЕ

Шушы елның 5 нче февралендә, иртән 9 сәгать 30 минутта, СССР ның Париждагы сәүдә вәкиллеге йортына, гражданский киемнәр киенгән йөзгә якын кеше басып керде. Сәүдә вәкиллегендә дежур торучы сотрудникка, бу кешеләрнең барсының да полиция префектының телдән биргән боерыгы буенча тентү ясау өчен килгәнлекләре белдерелде. Барлык телефон аппаратларын өзеп, полиция агентлары сәүдә вәкиллеге хезмәтен үтәүче иптәш Евстратовның хезмәт кабинетына һәм квартирасына үтеп керделәр һәм аның протест белдерүенә дә карамастан, анда тентү ясарга керештеләр. Сәүдә вәкиллегендә тентү вактында шкафларны һәм сейфларны ватып документларны алдылар. Сәүдә вәкиллегенең хезмәткә килгән сотрудниклары тотылып полиция карамагы астында квартираларына озатылдылар һәм анда да шулай ук тентү ясалды. Шул ук вакытта интурист һәм Париждагы элекке совет мәктәбе йортларында да шундый ук тентүләр ясалды. Шуннан соң сотрудниклар азат ителделәр.

Тентү булу турындагы хәбәрне ишетү белән үк СССР ның Париждагы илчесе иптәш Суриц бинадан тизлек белән чыгып китүне һәм документларны кире кайтарып бирүне таләп итеп, ике сотрудникны сәүдә илчелегенә җибәрде.

Полиция бу таләпләрне үтәүдән баш тартканнан соң, иптәш Суриц шул ук көнне 17 сәгатьтә полиция властьларының хәрәкәтләренә каршы Франция хөкүмәтенә протест белдерде, тентү ясауны туктатуны һәм барлык документларны сәүдә вәкиллегенә кайтарып бирүне таләп итте. (ТАСС).

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 7 февраль. Сугыш хәрәкәтләре турында кичә кич белән Парижда иглан ителгән рәсми белдерүдә: „Саардан көнбатыштагы районда патрульләрнең җирле хәрәкәтләре күренде“ диелә.

Иртәнге белдерүдә „фронтта яңа бер нәрсә дә булмады“ диелә.

БЕРЛИН, 7 февраль. Германия информация бюросы Германия армиясе верховный командованиесенең түбәндәге сводкасын тапшыра: „Меттлах белән Пфальц урманы арасында артиллериядән сирәк кенә атышуларны һәм патрульләрнең җанлы хәрәкәтләрен исәпләмәгәндә, көнбатыш фронтта әйтерлек вакыйгалар булмады. Мозельдән көнчыгышта патрульләр арасында сугыш булды, нәтиҗәдә бер герман солдаты үтерелде“.

БЕРЛИН, 7 февраль. Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Швециянең „Дагенс нюхетер“ газетасы Швециянең „Пайала“ пароходының батырылуын яза. Газета, пароходның кисәтүсез батырылганлыгын күрсәтә. Шушы уңай белән авторитетлы даирәләрнең әйтүенчә, 21 нче январьда ук инде Швециянең „Свенска дагбладет“ газетасы „Пайала“ пароходы капитанының хәбәрен урнаштырган. Бу хәбәрдә, пароходның Англия хәрби карабы күзәтчелегендә Киркуоллга (контрольный пунктка) алып киткәнлеге әйтелә. Германиянең авторитетлы даирәләре мондый хәл кабатланмасын өчен бу вакыйгадән файдаланырга кирәк дип саныйлар. Дошманның сугыш караблары тарафыннан озатылып баручы пароходларның, кайсы илнеке булуларына да карамастан, сугыш хәрәкәтләреннән килеп чыга торган барлык куркынычларга очраулары мөмкин. Бу, Германиягә дошман булган илләрнең сугыш караблары конвое астында озатылырга ирекле рәвештә ризалык биргән пароходларга да, дошман караблары тарафыннан көчләү юлы белән озатыла торган пароходларга да кагыла. Өченче дәүләт озатылуның ирекләме яки ирексезме икәнен белә алмый. „Нейтраль илләрнең эше,—диелә белдерүдә,—Англиянең мыскыллау практикасына каршы кискен протест белән чыгудан гыйбарәт“. (ТАСС).

АК ФИНЛЯНДИЯДӘГЕ ХӘЛ ТУРЫНДА АМЕРИКА МАТБУГАТЫ

НЬЮ-ЙОРК, 7 февраль. (ТАСС) Американың реакцион газеталары соңгы вакытка кадәр еш кына „фронттан“ дигән хәбәрләр урнаштырып килделәр. Бу хәбәрләрдә ак финнәрнең „җиңүләре“ турында фантастик уйдырмалар китерелде. Америка җәмагатчелеге мондый хәбәрләрне гаят зур ышанычсызлык белән каршы алды. Күп кенә шәһәрләрнең халыклары бу ялган информацияләргә карата ачыктан-ачык ризасызлык белдерделәр һәм реакцион матбугатның советка каршы кампаниясенә протест ясадылар. Хәзер хәтта кайбер реакцион газеталар да, Финляндиядәге сугыш хәрәкәтләре турында үзләре басып чыгарган хәбәрләр хәбәрчеләрнең үз күзәтүләренә түгел, бәлки ак финнәрнең белдерүләренә нигезләнгәнлекне танырга мәҗбүр булдылар. Ак финнәрнең „җиңүе“ турында матбугатта хәбәр ителгән сугышларны үзләре күрмәгәнлекләрен хәбәрчеләр үзләре дә икрар итәләр. „НЬЮ-ЙОРК геральд трибюн“ газетасының хәзерге вакытта үзәк Финляндиянең төньяк өлешендәге хәбәрчесе Керр, ак финнәр командованиесенең хәбәрчеләргә читтән тыш ышанычсыз каравын һәм фронтка җибәрмәвен хәбәр итә. „Чикаго дейли ньюс“ газетасының хәбәрчесе үзенең „орудиядән 3 тапкыр атканлыкны гына ишеткәнлеген“ белдерә. Ул Петсамоның совет гаскәрләре тарафыннан алынуы турында ак финнәр командованиесенең ике ай буена чит ил хәбәрчеләренә информация бирмәгәнлеген күрсәтә.

Ак финнәрнең тәмам эштән чыгу чигендә торуы турында Америка матбугаты торган саен ешрак яза. „Балтимор сэн“ газетасы „финнәрнең җиңелүе котылгысыз“ ди. „Вашингтон стар“ газетасының хәбәрчесе, „финнәрнең ресурслары тәмам бетте“ һәм алар „һәлакәт чигендә торалар“ дип яза.

„Чикаго дейли ньюс“ ның Хельсинкидан Стокһольмга килгән хәбәрчесе, Финляндиядә „Советлар Союзына теләктәшлек күрсәтүдә шикле булган күп кенә санда кешеләрнең кулга алынуларын“ раслады.

Полякларның Вильнодагы террорчылар оешмасы турында Германия газетасы

БЕРЛИН, (ТАСС) „Кенигсбергер альгемейне цейтунг“ газетасының язуына караганда, полякларның Вильнода фаш ителгән террорчылар оешмасы Англия һәм Франция тарафыннан төзелгән булган һәм алардан заданиеләр һәм корал алып торган. Газетаның язуына караганда, бу оешманың бөтен Вильно өлкәсендә таралган челтәре булган һәм Вильноның төрле урыннарында күп кенә корал яшергән. Вильно университетында корал склады табылган. Күп кенә кешеләрне кулга алуга да карамастан, поляк террорчылары оешмасы һаман да үзенең эшен туктатмый.

Шунысы характерлы, Англия һәм Франция Вильнода полякларга начар карыйлар дигән булып Литваның чит ил эшләре министренә „протест“ белдергәннәр. Газета, көнбатыш державалар Вильно өлкәсен төрле политик интригалар үзәгенә әверелдерергә маташалар дип яза.

АНГЛИЯ—ФРАНЦИЯ БЛОГЫНЫҢ ЛИТВАДА КАЗЫНУЫ

КАУНАС, 7 февраль. (ТАСС). Шушы көннәрдә Вильнода Польшаның заговорчы офицерларының икенче оешмасы фаш ителде. Англия—Франция блогы җитәкчелегендәге бу оешма үзенең теләге итеп Литва дәүләтен җимерүне куйган. Хәбәрләргә караганда, Литва властьлары бу оешмада торучылардан 80 нән артык кешене кулга алганнар.

Әйтүләренә караганда, моңа кадәр хөкүмәт башка илләрдән яшерен рәвештә килүче полякларны качаклар сыйфатында теркәп барган булган. Хәзер исә заговорлар фаш ителү уңае белән, Литва чиген яшерен рәвештә үтеп чыгучы барлык поляклар кире җибәреләләр дигән боерык чыгарылды.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

БЕР РАЙКОМНЫҢ УТЫРЫШ ҮТКӘРҮ ПРАКТИКАСЫ

Партиянең Кызыл Армия райкомы бюро утырышын көндезге 12 сәгаткә билгеләгән иде, ул бер сәгаткә соңга калып башланды.

Райкомның алдан белдергән көн тәртибе буенча беренче мәсьәлә—партиягә кабул итүләр. Ләкин, райкомның икенче секретаре иптәш Мөхәмәтҗанов бюро утырышына җитәкчелек итүче буларак, яңа бер „чираттан тыш" мәсьәлә китереп чыгарды. Ул мәсьәлә шактый вакытны алды. Аннары инде чираттагы беренче мәсьәлә карала башланды. Бер гаризаны тикшереп, икенчесен карарга дип торганда, тагын бер персональ эш килеп чыкты. Бу эшне карап бетергәндә утырыш башлануга 6 сәгать 45 минут вакыт үткән иде инде. Шуннан соң чираттагы беренче мәсьәләгә яңадан кайтып, 3 гариза тикшерелде.

Көн тәртибендә икенче мәсьәлә итеп партиягә кабул итүләр һәм яңа кабул ителгәннәр белән эшләү турында ике башлангыч партоешманың доклады тыңланырга тиеш иде. Авыллардан килүчеләр белән хисаплашмау гадәт булып киткәнлектән, бу мәсьәлә соңгарак тикшерүгә калдырылды. Аның урнына көн тәртибендәге 4 нче мәсьәлә (РОКК оешмасы турында) куелды. Шуннан соң кышкы агротехника чаралары турында каралды. Аннары гына көн тәртибендәге икенче мәсьәләгә чират җитте. Бу мәсьәләгә күчкәндә вакыт төнге беренче 55 минут иде инде.

Утырыш шуның белән тәмам була дип торганда, „төрле мәсьәләләр" килеп чыкты. Шулай итеп, утырыш төнге 2 сәгать 45 минутта гына тәмам булды.

Болай озакка сузылган утырыш Кызыл Армия райкомы өчен очраклы хәл түгел, бу—гадәттәге утырышларның берсе.

Утырыш карамагына куелган мәсьәләләрнең берсе дә алдан ныклап хәзерләнмиләр. Персональ эшләрне тикшерүгә кирәгеннән артык күп вакыт китә. Мондый мәсьәләләрне тикшергәндә райком членнарының кайберләре тарафыннан урынлы-урынсыз сораулар бирелә, бу сораулар кай вакытларда допроска да әйләнеп китәләр. Утырышта информация ясаучы кешеләргә бер-бер артлы туктаусыз сораулар бирүдә иптәш Мөхәмәтҗанов барыннан да уздыра. Кышкы агротехника чараларының үтәлеше турында район җир бүлеге мөдире 20 минут сөйләде. Шуның 10 минуты Мөхәмәтҗановның сорауларына җавап бирүгә китте. Бу мәсьәлә буенча колхоз председательләре дә информация ясарга тиешләр иде. Ләкин аларга сөйләргә туры килмәде, алар утырыш җитәкчесенең сорауларына җавап кына биреп тордылар. Сорауларның күбесе допрос формасында булды.

Утырыш барышында иптәш Мөхәмәтҗановның аерым принципиаль мәсьәләләрдә үзенчә генә эшләргә омтылуы, бюро членнарының фикере белән хисаплашырга теләмәве ачык күренде. Мәсәлән, Тат. Ялтан МТС ы партоешмасы секретаре иптәш Шәйдуллингә ял бирү мәсьәләсен хәл иткәндә, бюроның барлык членнары аңа ял бирү ягында торуга карамастан, Мөхәмәтҗанов үз сүзен үткәрү өчен мәсьәләне тавышка куймаска теләде. Райком членнары: „бу—демократияне бозу була" дип нык тора башлагач кына ул, гомуми фикергә кушылганлыгын әйтте. Ләкин ул һаман да үзенчә итте, мәсьәләне тавышка куймады.

Райком утырышына колхозлардан 18 кеше чакырылган иде. Аларның күбесе көндезге 12 дән алып төнге 12 гә кадәр көтеп утырдылар. Утырышка кирәкле кешеләрне билгеле бер сәгатькә чакыру гадәте райкомда бөтенләй юк. Райком җитәкчеләре шулай көтүне үзләренчә нормаль хәл дип уйлыйлар, күрәсең.

Кызыл Армия райкомындагы мондый яраксыз практиканы һич кичекмәстән бетерергә кирәк. Райком җитәкчеләренә бюро утырышларын алдан ныклы хәзерлек белән, планлы тәртиптә, үз вактында һәм берәүнең дә вактын әрәм итмәслек итеп, җидди төстә үткәрү искусствосына өйрәнергә кирәк. Райкомда, бигрәк тә персональ эләләрне хәл иткәндә кешеләргә иптәшләрчә һәм игтибарлы караш күрсәтергә кирәклекне бер вакытта да хәтердән чыгарырга ярамый.

Д. Кузнецов.

ВКП(б) Өлкә Комитеты инструкторы.

КОЛХОЗ ПАРТОЕШМАСЫ АКТИВ ЭШ АЛЫП БАРА

Норлат районы, „Активист" колхозы янындагы башлангыч партоешма (секретаре иптәш Сафа Фатыйхов) соңгы вакытта үзенең эшен шактый яхшыртты.

Оешманың барлык эшләре план буенча алып барыла. Коммунистлар партоешманың эш планнарын төзүгә, партҗыелышларның көн тәртипләрен билгеләүгә актив катнашалар. Оешмада 17 коммунист исәпләнә. Аларның барсы да колхозда агитаторлар һәм стена газеталарында редакторлар, редколлегия членнары булып эшлиләр. Агитаторлар колхозчылар, һәм колхозчы хатын-кызлар арасында политик-масса эшен җәелдерәләр. Коммунистлар үзләренә йөкләнгән эшләрне намус белән үтиләр.

ВКП(б) члены иптәш Әлмиев терлекчелек фермасының мөдире һәм анда эшләүчеләр арасында агитатор булып тора. Ул аларга партия һәм хөкүмәт карарларын аңлату эшен алып бара. Иптәш Әлмиев Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә булган иде. Ул андагы тәҗрибәләрне үзе җитәкчелек итә торган фермага күчерә. Фермада стахановчылар мәктәбе оештырды һәм аның эшен үрнәкле итеп куйды.

Партоешма политик эшне хуҗалык эшләре белән бергә бәйләп алып бара. Колхоз производствосында үрнәкле эшләүчеләрнең тәҗрибәләрен өйрәнә һәм аларны барлык колхозчыларга күчерә. Партоешманың көндәлек контроле һәм конкрет ярдәм итүе нәтиҗәсендә, колхоз узган елның хуҗалык бурычларын уңышлы төгәлләүгә ирешә.

Партоешманың уңышлары күп әлбәттә, ләкин шулар белән бергә аның эшендә җитешмәгән яклар да юк түгел әле. Мәсәлән, яшь кадрларны политик тәрбияләүгә игтибар җитәрлек түгел. Партоешма колхозда җитәкче эшләргә күтәрелгән яңа кадрларны идея-политик яктан тәрбияләргә, алар турында көндәлек кайгыртучанлык күрсәтергә, аларның большевизм рухында чыныгуларына ирешергә тиеш.

Афзал Җәлал.

КАНДИДАТЛАР АРАСЫНДА ЭШЛӘҮНЕ ЯХШЫРТЫРГА

ВКП(б) ның Сталин райкомы партиянең XVIII нче съездыннан соң узган вакыт эчендә ВКП(б) сафларын Ленин—Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән алдынгы кешеләр хисабына үстерүдә үзенең эшен шактый яхшыртты. Бу районда 1939 нчы елны ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 820 кеше һәм ВКП(б) членнары итеп 369 кеше кабул ителде. Партиягә яңа алынганнар арасында эшчеләр 263 кеше, комсомолецлар 323 кеше, инженер һәм техниклар 31 кеше, хатын-кызлар 263 кеше.

ВКП(б) сафларына яңа алынучылардан күп кенә иптәшләр, политик белемнәрен күтәрү өстендә системалы рәвештә эшләп киләләр. „Ширпотреб" артеленең председателе иптәш Иванов „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлегеннән өйрәнә. Ул политик темаларда докладлар ясарлык дәрәҗәдә үсеп җитте. Октябрь Социалистик Революциясенең XXII еллыгы турында һәм халыкның явыз дошманнары тарафыннан иптәш Кировның үтерелүенә 5 ел тулу уңае белән артель членнары җыелышын да докладлар ясады. ВКП(б) членлыгына кандидатлардан 822 кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н үзлекләреннән һәм 147 кеше түгәрәкләргә йөреп өйрәнәләр.

Партия сафларын үстерү буенча Сталин районында шундый уңышлар булу белән бер рәттән, эшнең бу тармагында зур гына җитешсезлекләр дә бар әле. Бу районда 351 кешенең ВКП(б) членлыгына кандидатлык стажлары күптәннән тулып узган, шулар эчендә 1929 нчы елдан кандидат булып торучы 2 кеше, 1929—1930 нчы елдан 6 кеше, 1931—1932 нче елдан 103 кеше, 1937—1938 нче елдан 240 кеше хисаплана.

Кандидатлар арасында эшләү мехкомбинат һәм ясалма каучук заводларында аеруча начар тора. Мәсәлән, мехкомбинатта 41 кеше һәм ясалма каучук заводында 30 кеше берничә елдан бирле ВКП(б) членлыгына кандидат булып торалар.

Стажлары үткән кандидатларны ВКП(б) га член итеп кабул итү буенча партиянең Сталин райкомы үзенең эшен яхшыртырга тиеш.

Ф. Хәмзин.

Допризывниклар ВКП(б) ның Лаеш райкомы партикабинетында.
С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ

МУЛ ИГЕН УҢЫШЫ ӨЧЕН

(„Сталин юлыннан"—Калинин район газетасы)

Мул иген уңышы өчен Сталинград өлкәсе бригадирлары тарафыннан башланган данлыклы хәрәкәт безнең Татарстан республикасы колхозларында һәм совхозларында да киң колач алды.

Сталинградлылар мөрәҗәгатенә беренче булып кушылган Калинин районының колхоз алдынгылары, йөзпотчылар хәрәкәтенең инициаторлары буларак, зур йөкләмәләр алдылар. Район үзенең йөкләмәсен практик тормышка ашыру өстендә хәзер киң күләмдә эш алып бара.

1940 нчы елда бөртекле культуралар буенча һәр гектардан кимендә йөз пот иген уңышы алырга! Калинин районының барлык колхозлары, МТС һәм совхоз коллективлары, районның барлык оешмалары әнә шуңа ирешү өчен көрәшкә тупланган. Кайбер звенолар (мәсәлән, „Октябрь" колхозының Сәитова һәм Сабиров звенолары) үзләренә беркетелгән участкыларда бөртекле культураларның һәр гектарыннан 60—65 центнер уңыш җыеп алырга йөкләмә алдылар. Алар моңа ирешү өчен планлы нигездә эш алып баралар.

Бу хәрәкәтне җәелдерү һәм йөкләмәләрне практик тормышка ашыру эшендә район газетасының булышлыгы аеруча зур.

„Сталин юлыннан" газетасы (редактор урынбасары иптәш Фәттахова) иген уңышын күтәрү бурычын принципиаль югарылыкка куеп, менә һәрбер номерында күренекле урын бирә. Язгы чәчүгә хәзерлек мәсьәләләренә карата соңгы ике айда газета 40 ка якын материал урнаштырды, дүрт баш мәкалә бирде. Алар барсы да бер төп максатны—социалистик авыл хуҗалыгы кырларыннан максимум уңыш яулап алу өчен большевистик көрәшне чагылдыралар.

Газета декабрь ае башында ук „1940 нчы елда югары уңыш өчен" дигән баш мәкаләсендә:

„Югары иген уңышы үзеннән-үзе килми. Аның өчен көрәшергә, хәзердән үк язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнергә... кирәк",—

дип язды һәм язгы чәчүгә хәзерлекнең барышын шул вакыттан алып тулы, системалы яктыртып килә.

Районның колхоз алдынгылары мөрәҗәгат кабул иткәннән соң, колхозларда, бригада һәм звеноларда йөз пот иген уңышы өчен киң күләмдә үзара социалистик ярыш башланган көннәрдә газета:

„Социалистик ярыш договоры кәгазьдә генә калмасын өчен, аның үтәлешен тикшереп тору һәм алдынгыларның эш тәҗрибәләрен массалаштыру белән колхоз правлениеләре һәм авыл советлары оператив җитәкчелек итәргә тиешләр"

дигән бурычны алга куйган иде. Газета моның да нәтиҗәлелегенә ирешә.

Газета битләрендә урнаштырылган: „Башлангыч эшләр" (12 декабрь), „Киров исемендәге совхозда" (24 декабрь), „Социалистик ярыш договоры үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре" (1 январь), „Язгы чәчүгә хәзерлек эшендәге кимчелекләрне бетерергә" (10 январь), „Договор үтәлешен тикшердек" (17 январь), „Тракторларга ремонт ясауны, ягулык һәм майлау материалларын ташуны тизләтергә" (21 январь), „Колхозда түгәрәкләрдә 140 кеше укый" (29 январь) дигән материаллар газетаның һәр тармакта һәм системалы, планлы эш алып баруын ачык күрсәтәләр.

„Сталин юлыннан"ның икенче уңышлы ягы, аның үз тирәсенә авыл хуҗалыгы белгечләрен тарта белүендә. Газета битләрендә аларга күп урын бирелә. Агрономнардан Сафиуллин, Ураев, Җәүһәрев, Шакиров, зоотехник—Шәйхеттинов, орлык тикшерү лабораториясе мөдире—Бариев иптәшләрнең берничә мәкаләләре басылып чыкты. Алар күп төрле актуаль мәсьәләләрне күтәрәләр, колхоз производствосының бөтен тармаклары буенча газета аша кыйммәтле киңәшләр бирәләр, тәҗрибәләр белән уртаклашалар. Мәсәлән, нинди генә һава шартларында булмасын, мул иген уңышы алуга ирешү өчен агротехника чараларының әһәмияте; стахановчылар мәктәпләре; звенолап эшләү; чәчү орлыгын хәзерләү һәм аны саклау чаралары; амбар корткычларына каршы көрәш; тирес һәм аннан файдалану; уңыш күтәрүдә җирле ашламаларның әһәмияте һәм аларны куллану; атны язга хәзерләү һәм башка шундый күп кенә темаларга материаллар еш кына урнаштырыла.

Орлык тикшерү лабораториясе мөдире иптәш Бариев „Алдынгыларның эш тәҗрибәләрен киң массага" дигән мәкаләсендә „Красный Октябрь" колхозының (Алтай крае) ефремовчы Морозов звеносы тәҗрибәләре белән колхозчыларны җентекләп таныштыра һәм, ефремовчылар кебек эшләгәндә, гектардан йөз пот кына түгел, бәлки 65—75 центнер иген уңышы алырга мөмкинлекне күрсәтә.

Гомумән, Калинин районының авыл хуҗалыгы белгечләре 1940 нчы елда мул иген уңышы яулап алу өчен көрәштә үзләренең мактаулы бурычларын намус белән үтиләр. Аларның газета битләрендә басылган материаллары колхозчыларга, колхоз кадрларына, тәҗрибәчеләргә гаять зур булышлык итә. Бу практиканы, авыл хуҗалыгы белгечләрен һәм тәҗрибәчеләрне газетада катнашуга тарту практикасын, киләчәктә дә ныгытырга һәм үстерергә кирәк.

Мул иген уңышы яулап алу өчен көрәштә „Сталин юлыннан" газетасы күпләргә үрнәк күрсәтә. Барлык район газеталары да шулай уңышлы эшли алалар. Моның өчен бары тик иген уңышын күтәрү мәсьәләләренә җидди әһәмият бирү, инициатива күрсәтү, эшләргә теләк булдыру гына таләп ителә.

Халык судларының эшен тагын да яхшыртыйк

И. В. КОРНЕВ
ТАССР юстиция халык комиссары.

Сталин Конституциясе, СССР ның, союзный һәм автономияле республикаларның суд төзелеше турындагы закон совет судының әһәмиятен тагын да югары дәрәҗәгә күтәрделәр.

„Суд үзенең бөтен эше белән СССР гражданнарын Ватанга һәм социализм эшенә чын күңелдән бирелгәнлек рухында, совет законнарын дөрес һәм тайпылышсыз үтәү, социалистик милеккә саклык белән караш, хезмәт дисциплинасы рухында, дәүләт һәм җәмагать бурычына намуслы караш, социалистик тулай көнкүреш кагыйдәләренә ихтирам рухында тәрбияли" (СССР ның, союзный һәм автономияле республикаларның суд төзелеше турындагы законның 3 нче статьясеннән).

Советлар иленең суд органнары алдына куелган бу зур һәм әһәмиятле бурычлар суд органнарының һәрбер работнигыннан җидди эш һәм җаваплылык таләп итә. Бу бурычны үтәү өчен көрәштә суд участкыларына кергән эшләрне үз вактында карап бару гаять зур урыннарның берсен тота. Суд участкыларында каралмый калган эшләрнең күп булуы эшләрне карауда волокита тудыра, шунын аркасында уголовный эшләр буенча җинаятчеләргә үз вактында тиешле удар ясалмый һәм ул эш үзенең барлык эффектын югалта. Волокита гражданлык эшләре буенча да эштә күп кенә кыенлыклар тудыра һәм хезмәт ияләренең интересларына зарар китерә.

Участкыларга кергән эшләрне вактында карауда республикабыздагы халык судлары, гомумән, яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр. Әгәр дә 1939 нчы елның беренче январена республикабыздагы барлык халык судларында каралмый калган эшләр саны бер айда кергән эшләрнең 100 процентын тәшкил итсә, 1940 нчы елның беренче январена каралмый калган эшләр саны бер айда кергән эшләрнең 29 процентын тәшкил итә. Халык судларының зур күпчелеге каралмый калган эшләр санын 10 көндә кергән эшләр саныннан да киметүгә ирештеләр.

Республикабызда халык судлары участкыларына кергән эшләрне карауда әле зур гына кимчелекләр дә яшәп килә. Судларда барлык эшләр 10 көн срок эчендә каралырга тиеш булуга да карамастан, 1939 нчы елда уголовный эшләрнең бары 22 проценты, гражданлык эшләренең бары 29,6 проценты гына 10 көн срок эчендә каралган. 1939 нчы елның декабрендә 10 көн срок эчендә каралган эшләр уголовный эшләр буенча 48, гражданлык эшләр буенча 65 процентка җитте.

Эшләрне карауның сыйфат ягына килгәндә, республикабыздагы судларда күп кенә җитешсезлекләр һәм ялгышлыклар бар әле. Мәсәлән, халык судларында каралган уголовный эшләр турында бирелгән жалобаларның 25,7 проценты буенча, гражданлык эшләр турында бирелгән жалобаларның 48 проценты буенча халык судларының приговорларын һәм карарларын ТАССР Верховный суды юкка чыгарды.

Бу китерелгән мисальләр, күп кенә халык судларының уголовный һәм гражданлык хокукын белмәүләрен, ә кайбер судьяларнең бу хокукны өстән генә, җиңелчә генә куллануларын күрсәтә. Приговорларның һәм карарларның юкка чыгарылуларының бу күп санлы фактлары кайбер судьяларнең процессуаль законнарны бозуларыннан килеп чыга.

Суд работниклары үзләренең политик белем дәрәҗәләрен югары күтәрергә, совет законнарын нык өйрәнергә тиешләр. Һәрбер эштәге материаллар суд тарафыннан бөтен җаваплылык белән алдан өйрәнелергә тиеш. Суд процессларын совет законнары таләпләренә тулысынча туры китереп үткәрергә кирәк. Бары тик шул вакытта гына суд эшенең сыйфаты югары дәрәҗәгә күтәрелер.

Политик әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне үтәүгә үз вактында керешә белмәү һәм аны үз вактында эләктереп ала алмау—Татарстандагы кайбер суд органнарының эшләрендә зур кимчелек булып тора. Мәсәлән, 1939 нчы елның көзендә крестьян хуҗалыкларының, бигрәк тә ялгыз хуҗалыкларның кайбер өлеше, шулай ук, аерым хәлләрдә, кайбер колхозларның җитәкчеләре дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәүгә саботажлык ясарга маташтылар. Шулай булуга да карамастан, суд-тикшерү органнары бу күренешләргә каршы көрәшкә бик соңга калып керештеләр. Язгы чәчүгә хәзерлек вактында фураж, чәчүлек орлыкларын урлау, аларны бозу, авыл хуҗалыгы инвентарьларына ремонт ясауга салкын карау фактлары да бар. Суд-тикшерү органнары мондый күренешләрнең барсына да тиз һәм дөрес чара күрергә тиешләр.

Суд процесслары гражданнарны совет законнары рухында тәрбияләүдә суд органнары кулларында төп метод булып торалар. Приговорларны һәм карарларны тиешле статьяләргә нигезләп чыгару гына җитми, бәлки һәрбер суд процессының әһәмиятен массаны тәрбияли алырлык югарылыкка күтәрергә кирәк. Суд процессларын масса катнашы белән, күргәзмә рәвештә үткәрүнең әһәмияте гаять зур. Ләкин кайбер судьялар моңа тиешле әһәмият бирмиләр. Менә, Юдино районының беренче участкы халык судьясе иптәш Ларионов. Ул соңгы кварталда бер генә эшне дә урыннарга, колхозларга чыгып карамаган.

Бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин халыкларның киң массасы белән һәр вакыт элемтә тотарга кирәклек турында безне, большевикларны өйрәтеп килде һәм өйрәтә. Суд работниклары иптәш Сталинның бу турыдагы күрсәтмәсен һәр вакытта исләрендә нык тотарга һәм аны үзләренең практик эшләрендә, халык алдында отчетлар ясау юлы белән, тормышка ашырырга тиешләр. Моны суд төзелеше турындагы законның 29 нчы статьясе дә таләп итә. Халык судьясе, масса алдында отчет биргәндә суд участкысының эше турында, үзенең эше турында, эштәге уңышлы һәм җитешсез яклар һәм ялгышлар турында сөйләргә тиеш. Судья үзенең отчетында аның участкысына кергән территориядәге җинаятьләргә һәм аның сәбәпләренә анализ ясарга, сайлаучыларга төп законнар турында сөйләргә тиеш. Башлычасы, сайлаучылар суд эшендәге җитешсезлекләрне актив рәвештә тәнкыйть итәргә һәм аларны бетерүне таләп итәргә тиешләр.

Республикабыздагы халык судьяләре тарафыннан 1939 нчы елда 822 отчет-доклады ясалды. Ләкин отчетларның саны җитәрлек түгел һәм, башлыча, кайбер судьялар ясаган отчетларның сыйфаты һич тә канәгатьләнерлек түгел. Дөрес, республикабызда судьяләрнең зур күпчелеге халык алдында отчет бирә. Болар хисабына Бондюг районының 2 нче участкы халык судьясе Архипов, Буа районының 1 нче участкы халык судьясе Иванов, Куйбышев районының 1 һәм 2нче участкылары халык судьяләре Арсентьев, Вәкилев иптәшләрне һәм башка күп кенә иптәшләрне күрсәтергә була. Алар сайлаучылар алдында системалы рәвештә отчет ясыйлар. Шуның белән бергә, бөтенләй отчет ясамаучы һәм бер - ике тапкыр отчет ясап тынычланып ятучылар да юк түгел әле. Менә Бөгелмә районының беренче, икенче участкылары халык судьяләре Маелаков, Кириллов, Молотов районының (Казан) 5 нче участкы халык судьясе Шебаршов иптәшләр. Алар суд эшендә җитәрлек дәрәҗәдә тәҗрибәләре булуга да карамастан, халык алдында бер генә тапкыр да отчет ясамаганнар.

Һәрбер халык судьясе суд төзелеше турындагы законның 29 нчы статьясен төгәл үтәргә—кимендә һәр айда 3 тапкыр халык алдында отчет ясарга тиеш. Докладларда гомуми сөйләнүләр түгел, бәлки суд участкысының конкрет эше күрсәтелергә тиеш. Шушы докладлар белән халыкның суд эшенә булган кызыксынуын тагын да күтәрергә кирәк.

Татарстан республикасы хезмәт ияләре йөзләрчә, меңнәрчә халык утырышчыларына уголовный һәм гражданлык эшләрне карауны ышанып тапшырдылар. Халык утырышчылары даими судьялар белән берлектә зур эшләрдән алып кечкенәләренә кадәр карыйлар. Ул эшләрне дөрес хәл кылу өчен һәрбер халык утырышчысы совет законнарының нигезләрен яхшы белергә тиеш. Халык утырышчыларының белем дәрәҗәләрен күтәрүдә аларга халык судьяләре конкрет булышлык күрсәтергә, халык утырышчылары белән занятиеләр үткәрергә, һәрбер халык утырышчысының юридик грамоталы булуына ирешергә тиешләр.

Суд органнары алдында торган эшләрнең кайберләре әнә шулар. Совет судының эше гаять җаваплы. Моны һәрбер суд работнигы, һәрбер халык утырышчысы яхшы белергә тиеш. Алар үзләренең бурычларын хөкүмәтебез, партиябез таләп иткән югарылыкта үтәү өчен, барыннан да элек, марксизм-ленинизмны, героик партиябезнең көрәш юлларын һәм совет законнарын нык өйрәнергә тиешләр.

Алда халык судьяләрен һәм халык утырышчыларын сайлаулар тора. Халык судьяләре һәм барлык суд работниклары бу сайлауларга большевикларча хәзерләнергә тиешләр. Суд органнары эшендә булган җитешсезлекләрне, волокита фактларын, закон таләпләрен бозуларны кискен рәвештә бетерү, суд органнарының эшләрен Сталин Конституциясе таләп иткән югарылыкка күтәрү — сайлауларга хәзерлектә иң әһәмиятле чара булыр.

ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРДӘ ЭЧКЕ МӨМКИНЛЕКЛӘРДӘН ТУЛЫ ФАЙДАЛАНЫЙК!

МАШИНАЛАРДАН ТУЛЫ ФАЙДАЛАНЫРГА

2 нче номерлы мех фабрикасының отделка цехында күп төрле эш процесслары башкарыла. Шуның өчен бу цех күп сандагы катлаулы машиналар белән җиһазландырылган. Хәзер анда 70 тән артык машина бар. Цехта производство планының үтәлеше нигездә шушы машиналарның тоткарсыз эшләүләренә бәйләнгән.

Ләкин цех җитәкчеләре бу күп сандагы машиналардан тулысынча файдалану, аларның эшләп чыгару куәтен арттыру мәсьәләсе белән җитәрлек шөгылләнмиләр. Колотилка машинасы хәзер минутына 600 оборот, кырку машинасы 800 оборот ясый. Техник яктан караганда бу машиналарның оборотын һәм эшләп чыгару көчен шактый күләмдә арттыру мөмкинлеге бар. Ләкин фабриканың инженер-техник көчләре, ни өчендер, бу мәсьәлә белән кызыксынмыйлар.

Запас частьләр булмау аркасында машиналар еш кына эшсез торалар. Мәсәлән, подшипник булмау аркасында 53 нче номерлы шомарту машинасы 4 айдан бирле, 24 нче номерлы колотилка машинасы ай ярымнан бирле эшсез торалар. Бу машиналарның эшсез торуына фабриканың тәэминат бүлеге мөдире Гусков һәм аның ярдәмчесе Николаев иптәшләр гаепле. Чөнки алар цехны запас частьләр белән, шулай ук майлау һәм чистарту материаллары белән үз вактында тәэмин итү чарасын күрмиләр.

Мех фабрикаларындагы барлык машиналарга капиталь ремонтны комбинатның механика заводы башкара. Машиналарга кирәк булган запас частьләр дә шушы ук заводта эшләнәләр. Ләкин механика заводына ремонтка бирелгән машиналарга бер кайчан да күрсәтелгән срокта ремонт ясалмый. Бу заводта айлар буе ремонт көтеп ята торган машиналар күп кенә.

Механика заводында эшләнгән запас частьләрнең сыйфаты да бик түбән. Кырку машиналарына куя торган спираль пычакларның сыйфаты чиктән тыш түбән. Бу пычаклар берничә сәгать эшләгәч тә үтми башлыйлар. Аларны кайрау өчен машинаны туктатырга туры килә. Ә отделка цехында берничә машина бер электромоторга беркетелгән. Шуның өчен бер машинаның пычагын кайрарга кирәк булса, берьюлы берничә машинаны эштән туктатырга туры килә. Мәсәлән, 3 нче агрегатта бер электромоторга 3 кырку машинасы, 6 колотилка машинасы беркетелгән. Димәк, бу агрегатка беркетелгән бер кырку машинасының пычагын кайрау өчен 3 кырку машинасын һәм 6 колотилка машинасын эштән туктатып торырга туры килә, дигән сүз. Менә бу хәл машиналарның бик күп вакытлар эшсез торуын китереп чыгара. Фабриканың өлкән механигы Драгункин һәм отделка цехы начальнигы Березин иптәшләр цехтагы машиналарның һәрберсенә аерым электромоторлар булдыру турында бик күп вакытлардан бирле сөйләнеп йөрсәләр дә, бу сөйләнүләрнең нәтиҗәсе күренми әле.

Үзенә беркетелгән машинаны чиста һәм культуралы хәлдә тоту һәрбер эшченең бурычы. Машиналарны үрнәк булырлык рәвештә чиста итеп тотучы стахановчылар отделка цехында аз түгел. Кырку машинасында эшләүче Карпова, Мөхитдинова, тарау машинасында эшләүче Иконникова, шомарту машинасында эшләүче Ефимова һәм Мостафина иптәшләр үз машиналарын күпләргә үрнәк булырлык итеп чиста тоталар. Алар машиналарның туктаусыз эшләве өчен көрәшәләр. Шуңа күрә бу иптәшләр планны һәр ай саен 120—150 процентка кадәр арттырып үтиләр.

Фабрика җитәкчеләре алдынгылар тәҗрибәсен артта калучыларга күчерүне, машиналардан тулы файдалануны большевикларча оештырырга тиешләр.

Ф. Сагдиева.

ТАТПРОМСОВЕТ АКТИВЫНЫҢ РЕСПУБЛИКА КИҢӘШМӘСЕ

5—6 нчы февральдә Татпромсовет активының республика киңәшмәсе булып үтте. Киңәшмәдә Татарстан промысло кооперациясенең 1939 нчы елгы эш йомгаклары һәм 1940 нчы елда алда торган бурычлар турында Татпромсоветның президиум председателе иптәш Варламов доклад ясады.

Халык хуҗалыгының башка тармаклары шикелле үк, Сталинчыл бишьеллык елларында Татарстан промкооперациясе дә шактый үсте. Бу системада 1938 нче елны 154 миллион 700 мең сумлык продукция эшләп чыгарылган булса, Сталинчыл өченче бишьеллыкның икенче елы—1939 нчы елда 188 миллион сумлык продукция эшләп чыгарылды. Тулай продукция буенча еллык план 104 процент итеп үтәлде.

Хәзер бу системаның 6 меңнән артык стахановчысы бар. 33 цех һәм күп кенә артельләр тоташ стахановча эшлиләр.

Фикер алышуларда катнашучы Шишкина, Назиров, Ибатуллина, Петряев, Степанов, Тимофеев, Ибатуллин һәм башка күп кенә иптәшләр Татпромсоветның һәм аның бүлекләренең артельләргә йомшак җитәкчелек итүләрен тәнкыйть уты астына алдылар һәм эшне яхшырту буенча конкрет тәкъдимнәр бирделәр.

Киңәшмәдә ВКП(б) Өлкә Комитеты секретарьлары Алемасов, Долатказин, ВКП(б) ның Казан Шәһәр Комитеты секретаре Бычков, Татарстан Халык Комиссарлары Советы председателе урынбасары Киселев һәм Всекопромсовет вәкиле Калинов иптәшләр катнаштылар.

Актив җыелышында Татпромсовет белән Башпромсовет арасында төзелгән социалистик ярыш договоры тикшерелде.

ЭЛЕКТР ЭНЕРГИЯСЕНӘ 3,8 ПРОЦЕНТ ЭКОНОМИЯ

Электр энергиясенә экономия ясау предприятие җитәкчеләренең, цех начальникларының, мастерларның һәм электромонтерларның иң әһәмиятле бурычларыннан берсе. „Спартак“ комбинатында хуҗалыкның бу әһәмиятле тармагына зур игтибар бирелә. Электр энергиясенә экономия ясау өчен бөтен коллектив көрәш алып барганга күрә дә зур гына уңышларга ирешелде. 1939 нчы хуҗалык елында без электро энергиясенә 3,8 процент экономия ясадык.

Бу зур уңыш, әлбәттә!

Комбинатның электр хуҗалыгында күп кенә тәртипсезлекләр бар иде. Энергиянең күпме тотылуы өстеннән контрольлек җитәрлек түгел иде. Без бу эштәге кимчелекләрне бетерүгә ирештек. Мәсәлән, комбинатның төрле корпусларында, цехларында һәм башка урыннарында кирәксезгә байтак лампалар яна иде. Без кирәге булмаган урыннардагы лампочкаларны алдык.

Аннары, энергия берничә моторга берьюлы бирелә иде. Аерым эш урыннарына күпме энергия кирәк булуын, аның күпме тотылуын белүче, бу эш белән кызыксынучы юк иде. Электр хуҗалыгындагы бу тәртипсезлекне дә бетерүгә ирештек. Без моторларга индивидуаль рәвештә электр энергиясе бирүгә күчтек. Бу эш комбинатта тулысынча хәл ителеп җитмәгән. Шулай да, ул эшнең хәзер шактый өлеше башкарылды инде. Комбинаттагы барлык моторларның куәтләре исәпкә алынды, аларга сынау үткәрелде. Бу сынау нәтиҗәсендә, без быел тагын 175 киловатт-сәгать электр энергиясенә экономия ясарга мөмкин булуын белдек.

Социалистик ярыш яхшы нәтиҗәләр бирә. Монтерлар электр энергиягә экономия ясау өчен үзара ярышып эшлиләр. Мәсәлән, иптәш Яшаркин электромонтер иптәш Потапов белән ярыша. Алар алган йөкләмәләрен үтәү өчен ныклы көрәш алып баралар. Электромонтер иптәш Яшаркин комбинатта озак еллардан бирле эшли. Аның тәҗрибәсе зур. Ул үзенең бай тәҗрибәсен башкаларга күчерә, электр хуҗалыгында гомуми күтәрелешкә ирешү өчен зур тырышлык күрсәтә.

Штамп цехы электро-монтеры иптәш Гыйльметдинов авариясез эшләүнең сокланырлык үрнәкләрен бирә.

Электр хуҗалыгы өлкәсендә әле кайбер кимчелекләр дә юк түгел.

Комбинатның тәэминат бүлегендә зур кимчелекләр кабатланып килә. Ул кирәкле материалларны һәм оборудованиеләрне вактында хәзерләми. Ә бу хәл монтерларның эшләренә зур комачаулык китерә. Аларның инициативаларына тоткарлык ясый. Бу уңай белән бер генә факт китереп үтик. Электромонтер иптәш Вахрушев „АГО“ прессында кыздыру приборларын алмаштыру турында бик әһәмиятле тәкъдим керткән иде. Ләкин тәэминат бүлеге бу тәкъдимне тормышка үткәрү өчен кирәкле материалларны табып бирмәде. Иптәш Вахрушевның тәкъдиме әлегә кадәр нәтиҗәсез ята. Киләчәктә мондый кимчелекләргә юл куелмаска тиеш.

Без быел электр энергиягә 5 процент экономия ясарга булдык. Бу йөкләмә үтәлерлек. 1939 нчы елның уңышларын ныгытып, без электр энергиясенә экономия ясау буенча алган йөкләмәбезне тулы үтәрбез.

Г. Будкин.

„Спартак“ комбинатының электр хуҗалыгы мөдире.

ЭКОНОМИЯ ӨЧЕН КӨРӘШМИЛӘР

Киез итек-фетр фабрикасы (Казан) соңгы вакытта шактый яхшы эшли башлады. Үткән елның октябрь-ноябрь һәм декабрь айлары планы, шулай ук бу елның январь ае планы да арттырып үтәлде. Продукциянең сыйфатын яхшырту өлкәсендә дә беркадәр уңышларга ирешелде.

Ләкин кимчелекләрне бетерүдә күп эшлисе бар әле. Үткән ел бу фабрика чимал белән кирәгеннән артык тәэмин ителгән иде. Шулай булуга карамастан, фабрикада үткән елгы план тулай продукция буенча 92,8 процент, ә натуралата бары тик 85,6 процент кына үтәлде. Шул ук вакытта еллык фонд буенча җибәрелгән чимал 19 тонна артык тотылды. Фабрика 70 мең сумнан артык зарар күрде. Илгә ун меңнәрчә пар киез итек биреп җиткермәде.

Фабрика җитәкчеләре, (директоры иптәш Вязовкин) чималны саклык белән тотуга хәзер дә тиешле игтибар биреп җиткермиләр. Мәсәлән, түшәү цехында киез итекләрнең күп өлеше төпсез, озын балтырлы итеп эшләнү аркасында, январь аенда гына да дистәләрчә тонна чимал артык тотылды. Ләкин фабрика җитәкчеләре чималны әрәм итүләргә каршы тиешле көрәш алып бармыйлар.

„Без, кечкенәләрдән алып зурларына кадәр, үзебезнең барлык работникларыбызның дәүләт һәм халык каршында җаваплы булуларын һәр вакыт истә тотуларына, халык байлыгын саклауда һәм аның белән хуҗаларча эш итүдә, расходларга экономия ясауда һәм халык акчасын чын-чынлап саклауда үзләренең бурычларын һәр вакыт исләрендә тотуларына ирешергә тиешбез!“ (Молотов).

Фабрика җитәкчеләре чималны экономия белән тоту, хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да үстерү өчен барлык чараларны күрергә тиешләр.

К. Х.



„Красный Путь“ заводы механика цехы стахановчысы Ф. Настин. Ул, эш нормасын 170 процент үти.

М. Солтанов фотосы.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ XXII ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

ХӘРБИ ЯРЫШЛАР

Казан Укытучылар йорты, Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы уңае белән, 12 нче февральдә ПВХО буенча ярышлар үткәрә. Ярышучылар газ белән агуланган җирләрне табу һәм зарарсызландыру, противогазны тиз кию, салу һәм башка төрләр буенча ярышачаклар.

17 нче февральдә укытучыларның һәм укытучылар хәзерләү курслары курсантларының „Ватан оборонасына хәзер бул“ дигән темада кичәләре була. Бу кызыклы кичәдә санитария звеносы членнары тарафыннан „Һәр йорт—оборона крепосте“ дигән инсценировка күрсәтеләчәк.

18 нче февральдә укытучыларның районара ярышлары үткәрелә. Ярышларда 50 гә якын укытучы катнашачак. Шулай ук шәһәр укытучылары өчен оборона кичәсе үткәрү күздә тотыла. Кичәдә „Антантаның өч походы, аларны тар-мар итү, гражданнар сугышында Кызыл Армиянең җиңүе“ дигән темада лекция булачак. Соңыннан Татарстан Дәүләт Филармониясе артистлары көче белән оборона тематикасына концерт биреләчәк.

Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты көнендә укытучыларның бәйрәмгә багышланган кичәсе үткәрелә. Укытучылар йортының җыр һәм бию ансамбле, шулай ук башка түгәрәкләр оборона җырлары, биюләре хәзерлиләр. Китапханәдә китап күргәзмәсе оештырылды. Балалар иртәлеген үткәрү күздә тотыла.

ЧАҢГЫ ПОХОДЛАРЫ

Кама Тамагы районының предприятиеләрендә, учреждениеләрендә һәм колхозларында Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең 22 еллыгына хәзерлек җәелдерелде. Оборона һәм физкультура оешмалары 23 нче февральгә кадәр хәрбиләштерелгән походлар, чаңгыда чыгышлар үткәрәчәкләр.

Пристаньнең 15 кеше составындагы чаңгычылар командасы 20 километрга—Куйбышев затонына чаңгы походы үткәрә. Чаңгычылар Кама Тамагы пристанендә беркетелгән судноларга ремонт ясауның барышын һәм анда масса-оборона эшләренең торышын тикшерәчәкләр.

23 нче февральдә районда ату ярышлары үткәрелә. Физкультурниклардан һәм допризывниклардан 50 кеше 10 километрга чаңгы походына барачаклар, каршылыкларны җиңү, чаңгыда барганда граната ыргыту һ. б. буенча ГТО значогына нормалар тапшырачаклар.

ТАССРның XX еллыгына хәзерлек

МЕХЧЫЛАРНЫҢ ЧАКЫРУЫНА ҖАВАП

Киров исемендәге 4 нче номерлы ясалма каучук заводы коллективы мехчыларның мөрәҗәгатен зур күтәренкелек белән каршылады. Бу мөрәҗәгатне цех һәм смена җыелышларында тикшереп, завод эшчеләре, инженер-техник работниклары һәм хезмәткәрләре хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү буенча конкрет йөкләмәләр алдылар.

Иптәш Суерова җитәкчелегендәге комсомолецлар сменасы мехчыларның чакыруына иң беренче булып кушылды. Бу смена ярты еллык планны 25 нче июньгә үтәргә булды.

3 нче номерлы цех стахановчылары Сидоров, Шлыгин һәм Козихин иптәшләр дә ике пичкә хезмәт күрсәтү методын тагын да киңәйтергә сүз бирделәр. Ясалма каучук промышленностенда ике пичкә хезмәт күрсәтү буенча беренче тапкыр кулланыла торган метод хәзер башка ясалма каучук заводларына да күчерелде.

Иптәш Мальцева җитәкчелегендәге смена коллективы Татарстанның XX еллыгына планнан тыш 200 тонна продукция бирү турында йөкләмә алды.

ТЕАТРЛАРДА

Республикабызның XX еллык бәйрәмен күнелле итеп уздыру өчен безнең театрлар бик күп нәрсәләр эшли алалар һәм, чынлап та, аларның кайберләре җиң сызганып эшкә керештеләр дә инде.

Мисаль өчен Татар Дәүләт Опера театрын алыйк. Бу театр XX еллык бәйрәмне „Галия Бану“ дигән яңа опера белән каршы алырга хәзерләнә. „Галия Бану“ операсы татар халкына бик таныш булган мәшһүр „Галия Бану“ драмасы мотивларына корылган, аның либреттосы шагыйрь Әхмәт Ерикәй тарафыннан язылып, музыкасы композитор Мозаффаровныкы. Опера халык моңнарына, фольклорга бик бай. Ул инде театрга тапшырылган, хәзер композитор иптәш Мозаффаров операны инструментка җайлау өстендә эшли. Артистлар үзләренең партияләрен өйрәнү һәм үзләштерү эшенә гаять зур энтузиазм белән керештеләр. Операны сәхнәгә режиссер Сарымсаков куячак. Дирижерлык эшен театрның музыка җитәкчесе, Татарстанның атказанган сәнгат эшлеклесе иптәш Бергольц алып барачак.

Яшь тамашачылар театры да бәйрәмгә хәзерлек төсендә күп кенә нәрсәләр эшләп ята. Татарстанның XX еллык бәйрәме көннәрендә театр татар әдәбияты классигы—язучы Ш. Камалның „Матур туганда“ дигән әсәрен русчага тәрҗемә итеп сәхнәгә куячак. Хәзерге көндә театр мәктәпләрдә булган үзешчән драмтүгәрәкләр өстеннән шефлык алып бара, квалификацияле артистлар җибәреп, художество һәм оештыру эшләрендә аларга практик ярдәмнәр күрсәтә.

Тик драма театрлары гына бу эштә ничектер селкенер-селкенмәс азапланалар. Зур драма театрында XX еллыкка хәзерлек буенча „җыелырга“ һәм „план төзәргә“ бары тик исәплиләр генә әле.

Шулай ук Татар Дәүләт Академия театрында да хәзерлек эше алай гөрләми. Биредә «бәйрәмдә нинди яңа спектакль күрсәтәчәкләрен әле шушы көнгә чаклы хәтта театрның җитәкче работниклары да белмиләр, ә бит Татар Академия театры дип аталган театрдан безнең күбрәкне сорарга да хакыбыз бар. Республиканың XX еллык тантанасы ул—татар совет сәнгатенең дә тантанасы.

Татарстанның сәнгат комитеты башланган эшләрне ныгыту һәм көчәйтү белән бергә, кайбер аерым театрларда хөкем сөрә торган сүлпәнлекне бетерү өчен дә практик чаралар күрер дип ышанып калабыз.

Ф.

Тел, әдәбият фәнни тикшерену институты

Татар телен, әдәбиятны фәнни яктан тикшерү һәм өйрәнү формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик культураны үстерүдә гаять зур әһәмиятле эшләрнең берсе. Республикабызда татар телен, әдәбиятны һәм фольклорны өйрәнү һәм тикшерү буенча фәнни институт оештыру мәсьәләсе күптән күтәрелгән иде инде. Һәм Татарстан АССР Совнаркомы карары буенча ул үткән елның август аенда Наркомпрос янында оештырылды.

Тел, әдәбият фәнни тикшерену институты алдында зур бурычлар тора. Алар институт советы тарафыннан расланган яңа положениедә бик ачык күрсәтелгәннәр. Институт, иң беренче чиратта, татар теленең, әдәбиятның һәм фольклорның нигезен, җинеп чыккан социализм чорында аларның юнәлешен, татар халкының рус телен өйрәнү мәсьәләсенең куелышын өйрәнү һәм тикшерү белән шөгылләнергә тиеш. Институт үзенең фәнни-тикшерену эшен үзәк фәнни тикшерену учреждениеләренең, тугандаш республикалардагы фәнни тикшерену институтларының, педагогия институтларының, укытучыларның белемнәрен күтәрү институтының, һәм башка шундый учреждениеләрнең, эшләре белән бергә бәйләп алып бара. Институт татар һәм рус телләренең, әдәбиятларының һәм фольклорының төп мәсьәләләре буенча фәнни докладлар үткәрә, классик әдәбиятларның, фольклорның академик басмаларын хәзерли.

Институтның эше бу яңа положениедә бик ачык күрсәтелгән. Ләкин, шуңа карамастан, институтка тагын башка төрле эшләрне, фәнни тикшерену институтына хас булмаган эшләрне йөкләргә маташучылар да юк түгел. Бу мәсьәләдә Наркомпросның артык аеруча зур „тырышлыгын“ күрсәтергә мөмкин. Бу, институтның Наркомпрос тарафыннан расланган беренче положениесендә бик ачык күренә. Наркомпрос ана теле һәм әдәбият буенча програмаларны, уку китапларын эшләүне, отличник укытучыларның эш тәҗрибәләрен өйрәнүне һәм аларны туплауны, тәҗрибә уртаклашуны институтның төп бурычларыннан берсе итеп куя. Һәм, нәтиҗәдә, укытучыларның белемнәрен күтәрү институтының, методик кабинетларның эшләре фәнни тикшерену институтына йөкләтелеп, алар арасында параллелизм тудыра. Институтның үткән елның 31 нче октябрендә булган совет утырышы мондый хәлне каты тәнкыйтьләде һәм институт тарафыннан яңа положение булдырылды. Ләкин эш моның белән генә чикләнми, яңа положение, дөрес эшләнүенә дә карамастан, бу көнгә кадәр тиешле оешмалар тарафыннан расланмаган. Моннан, фәнни тикшерену институты мәктәпләр белән шөгылләнергә тиеш түгел дигән нәтиҗә ясарга ярамый, билгеле. Киресенчә, институт үзенең практик эшендә мәктәпләр белән, укытучылар белән тыгыз элемтәдә булырга тиеш.

Шулай ук, институтның тулы хуҗасы да бу көнгә кадәр билгеле түгел. Күп кенә башка республикаларда фәнни тикшерену институтлары Совнарком янында оештырылганнар һәм Совнарком җитәкчелегендә эшләп киләләр. Казан институтын да Татарстан АССР Совнаркомы янында оештыру турында РСФСР Совнаркомының махсус карары бар. Ләкин бу карарның тормышка ашырылганы юк әле.

Институт үзенең оештыру чорын гына үтүгә дә карамастан, фәнни тикшерү эшләрен җәеп җибәрде инде. Ул төп кадрлар белән нигездә тупланган, татар теленең библиографиясе төзелеп ята, татар халкының революциягә кадәр булган чордагы фольклоры буенча институт зур эш алып бара. Синтаксис һәм морфология буенча материаллар тупланган. 1940 нчы ел өчен институтның тематик планы һәм секторларның эш планнары төзелгән.

25 нче январьда булып үткән совет утырышы институтның 1940 нчы ел өчен төзелгән шушы тематик планны тикшерүгә багышланган иде. Совет тарафыннан расланган план буенча институт алдына гаять зур бурычлар куела. Быел институт татар әдәбияты секторы буенча татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайның академик басмасын хәзерләргә тиеш. Бу академик басма 3 том булып, шуның беренче томы быел ук чыгарылырга тиеш. Тел секторы буенча татар теленең фәнни грамматикасын булдыру күздә тотыла. Рус теле секторы буенча рус һәм татар теленең чагыштырма грамматикасын булдыру өчен тулы материал туплау һәм фольклор секторы буенча 40—45 басма табак күләмендә татар фольклорының җыентыгын чыгару эшен алып бару бурычы куела.

Совет утырышында катнашучы иптәшләр план белән тулысынча килешеп, үзләренең аерым фикерләрен дә әйтеп үттеләр. Гыйльми сүзлекне, орфография сүзлеген булдыру турында институт планында бер сүз дә әйтелми. Бу мәсьәләне тиз арада һәм тулысынча хәл итүне тормыш үзе таләп итә. Татар язуының рус графикасы нигезендәге яңа алфавитка күчерелүе уңае белән орфографик сүзлек, һич шиксез, тиз арада хәл ителергә тиеш. Билгеле, бу сүзлекне институт 4—5 ай эчендә генә хәл итә алмый. Мондый җидди мәсьәләне өстән генә хәл итү мөмкин түгел. Ләкин аерым сүзләрне дөрес язу буенча, бигрәк тә, „ж“ һәм „е“ хәрефләре белән башлана торган сүзләрне, „игтибар“, „сәгат“, „шагыйрь“, „шигырь“ һәм башка шундый сүзләрне дөрес язу буенча кулланма эшләгәндә, һич шиксез, яхшы булыр иде һәм мондый сүзләрне язуда булган буталчыклык тиз арада бетерелер иде. Институт бу мәсьәләне планнан тыш та эшли ала һәм эшләргә тиеш.

Институтның быелгы эш планы гаять зур. Һәм аны бары тик институтның үз көче белән генә үтәп чыгуы мөмкин түгел. Бу эшкә Татарстанның барлык фәнни көчен тартырга кирәк. Институтның җитәкче работниклары шушындый кадрлар турында уйларга тиеш иделәр. Ләкин эш планын тикшергәндә бу нәрсә күренмәде. Кадрлар хәзерләү һәм булган кадрлардан, штаттан тыш авторлардан дөрес файдалану, аларны институт тирәсенә туплау беренче чираттагы эшләрнең берсе. Һәм бу мәсьәлә никадәр тизрәк хәл ителсә, институтның эше дә шул кадәр яхшы барачак.

Татарстанда тел һәм әдәбият фәнни тикшерену институтын оештыру—ул, социалистик культураның үсешендә тагын да бер адым алга атлау. Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә татар халкы культурасының зур адымнар белән үсүе татар телен, әдәбиятны фәнни яктан тикшерү мәсьәләсен куйды һәм фәнни тикшерену институты барлыкка килде. Татар телен, әдәбиятны, фольклорны фәнни яктан тикшерү буенча практик эш башланды. Институтның эшен дөрес оештыру, ана большевистик җитәкчелек булдыру, фән работникларын институт тирәсенә туплау—алда торган бурыч әнә шул.

Институт үзенең бөтен эшен „фән өчен, аның чәчәк атуы өчен... Халыктан аерылмаучы, үзен халыктан ерак тотмаучы, бәлки халыкка хезмәт итәргә хәзер торучы, фәннең барлык казанышларын халыкка бирергә хәзер торучы, халыкка ирексезләп түгел, бәлки ирекле рәвештә, теләп хезмәт күрсәтүче фәннең, шундый фәннең чәчәк атуы өчен“ юнәлдерергә тиеш.

Рим Баһау.

ЛАТИН АМЕРИКАСЫ ИЛЛӘРЕНДӘ АКШ БЕЛӘН АНГЛИЯНЕҢ КӨРӘШЕ

АКШ империалистлары Латин Америкасына басып керергә маташалар. Үзәк Америка илләрен дә Нью-Йорк банкирлары үзләренең йогынтыларын барлык чаралар белән ныгыталар. Алар Куба, Гаити, Никарагуа һәм Колумбия ярларына үзләренең крейсерларын күп тапкырлар җибәрделәр инде. Алар анда восстаниеләр оештырдылар, десантлар төшерделәр, буйсынмаучыларны рәхимсез тармар иттеләр һәм юк иттеләр. Колумбия территориясенең иң яхшы өлеше тартып алынды һәм анда „бәйсез“ Панама төзелде. Никарагуа территориясендә АКШ гаскәрләре 25 ел буена хөкем сөрделәр. Хәзерге президент Франклин Рузвельт Вильсон кабинетында диңгез министре ярдәмчесе булган вакытта Америка армиясе һәм Американың хәрби диңгез көчләре Мексиканың күп кенә шәһәрләрен, Гаити һәм Сан-Доминго дәүләтләрен басып алдылар.

1928 нче елны Герберт Гувер президент сайлауларында җиңгәннән соң Латин Америкасына сәяхәт ясады. Шул чагында „Нью-Йорк Таймс“ газетасы, 1927 нче елны АКШ ның Латин Америкасына үзенең төп өч конкуренты—Англия, Франция һәм Германия барысы бергә сатканга караганда күбрәк товар сатканлыгын һәм шуннан элекке 8 ел эчендә Нью-Йорк банкирларының Латин Америкасына барлык башка илләрнең банкирлары салган капиталга караганда 6 тапкыр күбрәк капитал салганлыгын язды. Бу вакытта АКШ Латин Америкасындагы 20 дәүләтнең 14 ендә үзенең хәрби политик яки финанс контролен урнаштырды.

Латин Америкасына АКШ ның тизлек белән үтүе Англия—Америка каршылыкларын кискенләштерде. Англия империализмы үзен Латин Америкасы илләреннән кысрыклап чыгаруга тоткарлык ясарга бөтен көче белән тырыша. Шулай да бу кысрыклану елданел көчәя. 1913 нче елны Англиянең Аргентинага товар кертүе Американыкына караганда 2,5 тапкыр, Бразилиягә 1,5 тапкыр, Чилигә 2 тапкыр артыграк иде. 1929 нчы елны инде АКШ Аргентинага һәм Бразилиягә Англия товар керткәнгә караганда 1,5 тапкыр артыграк, ә Чилигә 2 тапкыр артыграк товар кертте.

Латин Америкасында Бөек Британия белән АКШ арасында көрәшнең кискенләшүе Яңа Дөньяның бу өлешендә күп кенә коралл конфликтлар булуга китерде: Парагвай белән Боливия сугышы һәм башкалар. Перу һәм Чили бакыры өчен, Венецуэла һәм Мексика нефте өчен, Боливия кургашыны, нефте һәм бакыры өчен, Бразилия каучугы һәм марганецы өчен көрәш яңа көч белән кабынып китте. Ләкин Англиянең үзенең югалткан позицияләрен кайтаруга булган барлык маташулары кирәкле нәтиҗәне бирмәделәр.

Соңгы елларда АКШ президенты Франклин Рузвельт, Латин Америкасы илләренә „экономик ярдәм“ дигән булып оста тактика кулланып, АКШ ның бу илләрдәге позицияләрен тагын да ныгытты.

Европадагы хәзерге сугыш уңае белән АКШ капиталы Яңа Дөньяның көньяк илләрендә үзенең эшен аеруча көчәйтте. Сентябрь аенда банк даирәләре органы „Уоллстрит джорнэл“ газетасы болай дип язды: „Европа мәшгуль булганлыктан, Америка фирмалары Латин Америкасында үз товарларын такдим итүне көчәйттеләр“. Сугыш уңае белән Англиянең Америка өчен „бушаткан“ базарларын Америка матбугаты ачыктан-ачык санап күрсәтә. Республикачылар партиясе органы „Нью-Йорк геральд трибюн“ газетасы, әгәр сугыш озакка сузылса, Англия һәм башка кайбер илләр бушаткан базарларда елына кимендә 800 миллион долларлык Америка товары сатарга мөмкин булачак дип язды. Бу исәпләр аерым алганда Англиядән Яңа Дөньяның көньяк илләренә сугыш вактында текстильдән башка әһәмиятле товарлар чыгаруның тыелган булуына нигезләнәләр. 1937 нче елны Англия Көньяк Америка илләренә 186 миллион долларлык күмер, 90 миллион долларлык электр аппаратлары һәм 76 миллион долларлык химия нәрсәләре чыгарган иде. Сугыш башлану белән бу товарлар бары тик Франциягә һәм Британия империясе колонияләренә генә чыгарырга рөхсәт ителә.

„Геральд трибюн“ газетасы, сугыш нәтиҗәсендә Латин Америкасы илләренең АКШ ка биргән заказлары 50 процентка артты, дип хәбәр итә. Бразилия АКШ ка күп санда паровозларга, вагоннарга һәм тимер юл рельсләренә заказ биргән. Американың корыч тресты Бразилиядә концессиягә тимер рудасы чыганаклары алган. Бу чыганаклар моннан 20 ел элек Англия компаниясенә бирелгәннәр иде, ләкин бу компания анардан файдаланмаган иде.

Аргентина АКШ тан күп кенә промышленность товарлары алуны чикләвен юкка чыгарды. АКШ ның автомобиль, авиация һәм электротехника промышленносты Аргентинага, Бразилиягә, Чилигә һәм Латин Америкасының башка илләренә товар чыгаруны киңәйтә.

АКШ империалистлары Англияне Латин Америкасыннан тәмам кысрыклап чыгару өчен Европадагы сугыштан файдаланырга омтылалар. Бу факт АКШ белән Англия арасындагы каршылыкларның мәңгегә беткәнлеге турында Британиянең политик эшлеклеләренең белдерүләре ялган икәнлекне тагын бер кат раслый. Бу гаять көчле ике империалистик дәүләт арасындагы төп каршылыклар әле дә сакланып калалар. Ныклы каршылыкларның берсе—Латин Америкасы базарлары өчен көрәш һәм әгәр икенче империалистик сугыш озакка сузылса Англиянең бу базарлардан тәмам кысрыкланып чыгарылуы мөмкин.

В. Лан.

ЯШ ЛЕЙТЕНАНТЛАР

7 нче февральдә Казан пехота училищесендә яш лейтенантларга чираттагы чыгарыш булды. Ике ел буе хәрби белемне ныклап өйрәнүләре, үзләренең политик белемнәрен күтәрү буенча өзлексез эшләүләре нәтиҗәсендә курсантларның 93 проценты училищене барлык фәннәр буенча отлично билгесенә, ә калганнары яхшы билгесенә тәмам иттеләр.

Яш лейтенантлар һәр яктан тулы хәзерлекле, физик яктан чыныккан, Ленин—Сталин партиясенә, сөекле юлбашчыбыз Сталинга чын күңелдән бирелгән патриотлар булып торалар. Менә йөзләрнең берсе—Василий Шанцев. Училищегә килгәндә аның хәрби белеме бөтенләй юк иде. Ул тырышып укыды һәм тиз арада уку отличнигы булды. Хәрби һәм политик хәзерлектә югары күрсәткечләр биргәнлеге өчен ул кат-кат бүләкләнде һәм почет тактасына язылды.

Училищене тәмамлап чыгучылардан Тарханов, Чесноков, Усов, Шичанин, Горбушко һәм башка иптәшләрне алыйк. Аларны училищедә белмәгән кеше юк. Алар дисциплиналылык һәм укуда өлгереш буенча барлык иптәшләргә үрнәк булдылар. Тырышып уку бушка китмәде. Бу иптәшләр училищене беренче категория буенча тәмам иттеләр. Аларның күпчелеге училищедә командирлар итеп калдырылды.

Училищене яңа гына тәмамлап чыккан яш лейтенантлар чыгарыш җыелышында Ватан ышанычын тулысы белән акларга, сугышчыларны Ватан эшенә чиксез бирелгәнлек рухында тәрбияләргә, Кызыл Армиянең көчен өзлексез ныгытырга сүз бирделәр.

Г. Низам.

АБЫЙСЫ УРНЫНА ЭНЕСЕ

Биектау районы, Бирюлидәге җәнлек асраучылык совхозы директорының улы лейтенант-очучы Виктор Дмитриевич Саламатин ак финнәргә каршы сугышта геройларча һәлак булган. Бу турыда иптәш Саламатин хезмәт иткән полкның командованиесе, аның ата-анасына „Улыгыз Ватан өчен сугышта һәлак булды“ дип хәбәр итте.

Иптәш Саламатинның атасы Дмитрий Павлович һәм анасы Анастасия Николаевна иптәшләр өченче уллары Алексейны Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе сафына—Виктор хезмәт иткән частькә алуны сорап, СССР оборона халык комиссары иптәш Ворошиловка заявление җибәрделәр. Аларның уллары Алексей дә иптәш Ворошиловка шул ук турыда үтенеч җибәрде.

„Наука“ спорт җәмгыяте Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең XXII еллыгы хөрмәтенә чаңгыларда Казан—Шеланга маршруты буенча хәрбиләштерелгән поход үткәрде. РӘСЕМДӘ: Чаңгычылар колоннасы походта.

Н. Костин фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ХУДОЖНИК Б. К. ТИМОФЕЕВНЫҢ 25 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ

Татарстанның күренекле художнигы Василий Кириллович Тимофеевның художниклык эшенә быел февраль аенда 25 ел тула.

Татарстан Совет Художниклары Союзы юбилейне үткәрү буенча махсус комиссия төзеде. Комиссия хәзер художникның эшләреннән күргәзмә хәзерли. Иптәш Тимофеевның күп кенә эшләре Советлар Союзының төрле шәһәрләре музейләрендә саклана. Мәсәлән, аның „Моторлаштырылган пехота“, „Пулеметны өйрәнү өстендә“ дигән һәм зур полотнога эшләнгән рәсемнәре Москваның Кызыл Армия Үзәк Музеендә. „Юл төзелеше“, „Бригадалар ярышы“ һәм башка рәсемнәре Чувашстан республикасы музеендә. Шулай ук Ленинград, Ульяновский, Йошкар-Ола һәм башка шәһәрләрнең музейләрендә дә аның күп кенә рәсемнәре бар.

Комиссия Казанда ачылачак юбилей күргәзмәсенә художникның барлык эшләрен тупларга карар бирде.

Юбилей күргәзмәсе Татарстанның Крайны Өйрәнү Үзәк Музеендә художество галлереясендә февральнең беренче яртысында ачылачак. Күргәзмәдә художникның 25 ел эчендә эшләгән 300 гә якын рәсем портрет һәм пейзажлары куелачак. Алар арасында Волга пейзажлары, Татарстанның мехкомбинатын һәм башка предприятиеләрен чагылдырган этюдлар сериясе, орденлы Татарстанның алдынгы кешеләренең Кызыл Армия командирлары һәм сугышчыларының портретлары, тарихи рәсем һәм башкалар бар.

Татарстан Совет художниклары союзы республиканың башлап баручы реалист художнигы иптәш Тимофеевның тормышына һәм эшенә 25 ел тулуга багышлап юбилей кичәсе үткәрәчәк.

Р. Н.

ОПЕРА ТЕАТРЫНДА

4 нче февральдә Татар Дәүләт Опера Театрында яш артистларга смотр постановкасы булды. „Качкын“ операсының баш рольләрендә, беренче тапкыр, яш артистлар уйнадылар. Кирамәт ролен артист Альмеев, Булат ролен Алеев, Аблай ролен Бичурин һәм Бикә ролен Булатова иптәшләр башкардылар.

Бу иптәшләр үзләренең рольләрен шома һәм тигез уйнап чыктылар. Яш артистлар җаваплы рольләрне уңышлы үти алуларын күрсәттеләр.

М.

СТАХАНОВЧЫЛАРНЫҢ ФӘННИ КОМАНДИРОВКАСЫ

Казан „Спартак“ комбинаты стахановчыларыннан, инженерларыннан һәм техникларыннан 25 кеше узган ел фәнни командировкаларда булдылар. Алар Москва, Ленинград, Киев, Харьков шәһәрләрендәге күн заводларында һәм аяк киемнәре фабрикаларында булып, союзның алдынгы предприятиеләренең кыйммәтле тәҗрибәләрен үзләштереп кайттылар. Шул уңай белән, соңгы елда рационаллаштыру буенча 62 тәкъдим тормышка ашырылды. Бу, комбинатка 610 мең сум экономия бирде.

„АГО“ цехы начальнигы иптәш В. Святславский олтаннарны ябыштыру өчен кулланыла торган җилемнең рецептын үзгәртте. Шуның аркасында комбинат 70 мең сум экономия алды. Стахановчыларның фәнни командировкалары нәтиҗәсе булган күп кенә кыйммәтле чаралар—штамп, парусин, экспериментал цехларында һәм комбинатның күп кенә башка цехларында да тормышка ашырылды.

1940 нчы елны фәнни командировкаларга тагын 25 кеше җибәрү күздә тотыла. (Тат ТАСС).

МЕДИЦИНА КАДРЛАРЫ ХӘЗЕРЛӘҮ

Казанда һәм районнарда кыска сроклы курслар аркылы ел саен күп санда медицина работникларны хәзерләнә. 1939 нчы елда Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты тарафыннан оештырылган курсларда 2.475 кеше хәзерләнә. Алар больницаларда, беренче ярдәм пунктларында, яслеләрдә һәм башка урыннарда эшлиләр.

Шушы көннәрдә Казанда кан күчерү һәм рентген белгечләре хәзерләү курслары ачылды. Бөгелмәдә, Чистайда, Кукмарада һәм Буада 2 айлык курслар аркылы 250 санитария инспекторы хәзерләнә. Колхоз яслеләре өчен 1.950 сестра һәм ясле мөдирләре хәзерләргә билгеләнде.

ШАХМАТ ЧЕМПИОНАТЫ АЛДЫННАН

Казан шахматчылары шәһәр беренчелеге өчен булачак турнирга хәзерләнәләр. Башка елдагы турнирлардан үзгә буларак, быелгы турнирда, СССР мастерлыгына кандидат иптәш Нәҗметтинев белән берлектә, беренче категория шахматчылары гына катнашачак. Катнашучыларның шундый көчле составы турнирның гаять кискен көрәш шартларында барачагын һәм шәһәр чемпионы иптәш Нәҗметтиневкә, чемпионлыкны саклап калу өчен, зур тырышлык куярга туры киләчәген алдан ук күрсәтеп тора. Катнашучылар исемлегенә хәзергә Колчурин, Сайгин, Хрусталев, Косалапов, Хенкин, Виноградов, Щербаков һәм Нотариус иптәшләр кертелде.

Шахмат-шашка клубында хәзер икенче категория шахматчылары турниры тәмам булып килә. Укучы Вельтмандер һәм Пиотровский иптәшләр инде тиешле норманы җыеп, беренче категорияле шахматчы дигән исемне алуны тәэмин иттеләр һәм, димәк, шәһәр чемпионатына катнашу хокукын алачаклар.

Шәһәр беренчелегенә турнир 12 нче февральдә башлана. Турнирда югары урынны алган иптәш беренче категорияле шахматчыларның Бөтенсоюз турнирына җибәреләчәк. 11 нче февральдә кич 7 сәгаттә, матбугат йортының утырышлар залында (шахмат-шашка клубында) катнашучыларның җыелышы була.

Х.

Күп балалы аналарга дәүләт пособиесе

1939 нчы елда Татарстанда күп балалы аналарга дәүләт тарафыннан 23 миллион 992 мең сум пособие бирелде.

Кайбыч, Чүпрәле һәм Буа районнарында күп балалы аналар башка районнардагыга караганда күбрәк. Кайбыч районында күп балалы аналар бер ел эчендә 572 мең сум, Чүпрәле районында—562 мең сум, Буа районында—554 мең сум пособие алдылар.

1940 нчы елда 9.222 кеше пособие алуда дәвам итәчәк. Бу аналарның 9.902 баласы өчен 19 миллион 842 мең сум пособие билгеләнде. Алар арасында ике бала өчен алучылар 600 дән артыграк исәпләнә.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

ҖИНАЯТЧЕЛӘР ЭЗЕННӘН. Татснабторг охраннигы Д. Жарковка, кичке 8 сәгаттә Банк урамында автомобильләр колоннасын саклаган вакытта, талаучылар һөҗүм иткәннәр. Җинаятчеләр Жарковны башына сугып екканнар һәм автомобильләрдән ике камераны алып киткәннәр. Җинаят эшләнгән урынга милиция работниклары кичекмәстән эзләүче эт китергәннәр. Эт Чернышевский урамындагы 17 нче йортның коридорына барып кергән. Анда камералар табылган. Аларны талап алып китүче Г. Разумов һәм П. Кульмин дигән җинаятчеләр кулга алынган.

Җаваплы редактор һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә, Наньнин—Биньян шоссесендә каты сугышлар дәвам итә. 4 нче февральдә японнар Юншаньнан 20 километр көнбатыштарак урнашкан кытай позицияләренә атака ясадылар, ләкин кире кагылдылар. Наньнин—Цинцчжоу шоссесендә кытай гаскәрләре, Гуанси һәм Гуандун провинцияләре чигендәге Даши пунктын алдылар.

Үзәк һәм Төньяк Кытайда артык үзгәрешләр булмады.

***

5 нче февральдә Япониянең 12 самолеты Шэньси провинциясенең төньяк-көнчыгыш өлешендәге Фугу шәһәрен бомбага тотты. Самолетлар 40 тан артык бомба ташладылар. Җимерелүләр һәм үлүче кешеләр күп түгел.

ТӨРКИЯДӘ ЯҢАДАН ҖИР ТЕТРӘҮ

БЕРЛИН, (ТАСС). Германиянең Трансоцеан агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 4 нче февральгә каршы төндә Төркиядә яңадан җир тетрәү булган. Бу юлы җирнең тетрәве үткән елдагы җир тетрәү вактындагыга караганда шактый көчлерәк булган. Алынган мәгълүматларга караганда, Эрзинджан районында 2 авыл бөтенләй җимерелгән. Җир тетрәү вактында 45 кеше үлгән, күп кеше яраланган.

ТӨРЛЕ ХӘБӘРЛӘР

■ 14 нче февральдә Москвада СССР гроссмейстере исеме алу өчен матч башлана. Бу шахмат матчында гроссмейстер Левенфиш һәм СССР мастеры Алаторцев очрашачаклар. СССР гроссмейстере дигән исемне алу өчен Алаторцев очколарның күбрәген алырга яки матчны ничья белән бетерергә тиеш.

■ Запорожье өлкәсенең Осипенко авылында Советлар Союзы Герое Полина Осипенкога памятник куелачак. Памятник кызыл граниттан ясалган ике метр биеклектәге бронза бюстан гыйбарәт булачак һәм биш метр биеклектәге пьедестальгә куелачак.

■ 1900 нче елның 7 нче февралендә бөек рус физигы—радионы уйлап табучы А. С. Попов дөньяда беренче тапкыр практик төстә ике яклы радио элемтә урнаштырды. Быел моңа 40 ел тулды. А. С. Поповның күренекле хезмәтләренә бары тик социализм илендә генә чын бәя бирелде. Сталинчыл бишьеллыклар елларында СССР да куәтле радиопромышленность төзелде, авыл хуҗалыгында, транспортта һәм промышленностьның төрле тармакларында радио элемтә челтәре киң җәелде. Рус галименең даһи уйлап табуы—радио культура революциясенең куәтле күтәргече булып әверелде.

Татар Дәүләт Опера театры
Татар Дәүләт Академия театры бинасында
Телефоннар: 30—78 һәм 29—04
Бүген, 9 нчы февральдә
КАЧКЫН
Талон 76.
7 сәгат 30 минутта башлана.
Культпоходлар оештыру буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
9 һәм 10 нчы февральдә
МАСКАРАД
Бүген талон 96.
11 нче февральдә
РЕВИЗОР
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ
СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ БҮЛЕГЕ
11 нче февраль, кич 6 сәгаттә Шәһәр Советының утырышлар залында, дәвалау-профилактик учреждениеләрнең җитәкчеләре белән берлектә,
Шәһәр Советы депутаты врачларның һәм медицина работникларының киңәшмәсен чакыра
Көн тәртибе: 1. Шәһәрдә сәламәтлек саклау эшләре һәм 1940 нчы елда алда торган бурычлар (докладчы сәламәтлек саклау халык комиссары иптәш Гинзбург). 2. Шәһәрдә сәламәтлек саклау эшендә Шәһәр Советы депутатларының катнашулары һәм аларның роле (докладчы РСФСР Верховный Советы депутаты профессор Агафонов).
Киңәшмәгә сәламәтлек саклау активы чакырыла.
Шәһәр Сәламәтлек Саклау бүлеге.
242—2—1

„СОЮЗКИНОПРОКАТ“ НЫҢ ТАТАРСТАН БҮЛЕГЕ
Шушы көннәрдә Татарстан АССР кино-экраннарына,
„Ленфильм“ тарафыннан эшләнгән

исемле тавышлы, художестволы яңа фильм бирде.
Картина „Пионер“ кино-театрында күрсәтелә башлады.
Фильм совет кешеләрендә бөек патриотизм, Ватанга кайнар мәхәббәт, ә дошманнарга карата тирән ачу булуы турында сөйли.
А. Апсолон сценариесе. Баш рольләрдә актерлардан— Н. Симонов, Ю. Толубеев, В. Лукин, О. Оверичева белән бергә Ленинград мәктәп балаларыннан—Юра Бычков, Вова Репкин һәм Рита Клокова катнаша.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
БҮГЕН һӘМ һӘР КӨН
Москва 4 нче труппасының
соңгы гастрольләре
ПОПУЛЯР КОМИК, һӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ,
РСФСР ның атказанган артисты, орденлы
М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик труппасы белән.
Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

„Союзмедзаготснаб“ ның
— Казан бүлеге —
шушы ел, 1 нче марттан
БЕТЕРЕЛӘ
„Союзмедзаготснаб“ ның Казан бүлегенә карата дәгъвалары булган барлык оешмалар, предприятиеләр һәм учреждениеләр ул турыда 1940 нчы ел, 15 нче февральдән дә соңга калмыйча белдерергә тиешләр.
Күрсәтелгән сроктан соң бирелгән дәгъвалар каралмаячак. ЛИКВИДКОМ.
205—1

ТАТЛЕСПРОМСОЮЗНЫҢ
„ДРЕВПРОМ“ АРТЕЛЕ
шушы ел, 1 нче февральдән
БЕТЕРЕЛӘ
Артельгә карата булган дәгъвалар 1940 нчы ел, 15 нче февральгә кадәр түбәндәге адрес буенча бирелергә тиеш: Казан, Киров урамы, 12.
Күрсәтелгән сроктан соң бирелгән дәгъвалар каралмаячак.
140—2—2

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да,	ФУТЛЯРДАГЫ КЕШЕ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН һӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4. 6, 8 һәм 10 да	УНБЕР БАШКАЛА
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	ПАРТИЯ БИЛЕТЫ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ПЭПО
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (2 нче сериясе)
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ҺАВА ПОЧТАСЫ

Казанда Федосеевский урамындагы
42 нче номерлы
2 КАТЛЫ ЙОРТ САТЫЛА
226—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 711 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 524.